БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 25 » июль 2018 ел № 266

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты төзелеш, архитектура һәм торак - коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында" 2018 елның 5 июлендәге 242 номерлы номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2.Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән затларга исәпкә кую һәм Дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күченеп килергә мәҗбүр булганнарга торак сатып алуга субсидияләр бирү өчен Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлекләренә кертү һәм авыл җирлегендә торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты. (4 нче кушымта).

1.5. Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (№5 кушымта).

1.6. Урынны торак урын дип, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.7. Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).

1.8. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә (реконструкцияләүгә), төзүгә (реконструкцияләүгә) рөхсәтләрнең гамәлдә булуын озайтуга (туктатуга), капиталь төзелеш объектларын төзүгә (реконструкцияләүгә) рөхсәтләргә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).

1.9. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта).

1.10. Рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (10 нчы кушымта).

1.11. Кадастр исәбенә кую максатыннан муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (11 нче кушымта).

1.12. Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (12 нче кушымта).

1.13. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (13 нче кушымта).

1.14. Күпфатирлы торак йортның беренче катында урнашкан фатирда балкон төзүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (14 нче кушымта).

1.15. Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (15 нче кушымта).

1.16. Җирлек территориясе өстендә авиация эшләре, парашют белән сикерүләр, һава судноларының күрсәтү очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, тагылма аэростатларны күтәрүне башкару өчен рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (16 нчы кушымта).

1.17. Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча автомобильдә авыр йөк һәм (яисә) зур габаритлы йөк ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (17 нче кушымта).

1.18. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (18 нче кушымта).

1.19. Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп, шәхси торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкарылуын тикшерү актын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (19 нчы кушымта).

1.20. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (20 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе Р. И. Шакиров